**СОВЕТ КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, п.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык тимер юл разъезды бистәсе, Гагарин урамы, 7

тел./факс 8(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**30 сентябрь 2020 ел** **№4**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советы тарафыннан 2018 елның 30 апрелендә кабул ителгән 81 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларының, җирле үзидарә сайланулы органнарының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру» карары, Коркачык авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " 30.04.2018 ел, № 81 карары белән расланган Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга, (Советның 24.09.2018 ел № 96, 03.12.2018 ел 108 нче номерлы карарлары редакциясендә).

2. 2020 елның 1 октябреннән Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында 30.04.2018 ел, № 181 Коркачык авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2020 елның 1 октябреннән арттырырга, (Советның

24.09.2018 ел № 96, 03.12.2018 ел 108 нче номерлы карарлары редакциясендә).

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11498 күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрелендәге 81 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары белән расланган 2 нче кушымта (Советның 2018 елның 24 сентябрендәге 96 номерлы, 2018 елның 03 декабрендәге 108 номерлы карарлары редакциясендә), таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: :

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләре күләме»

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 12 группа |
| Авыл җирлеге башлыгы | 15759 |

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Салихҗанов